КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 20 июль г.Казань № 612

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Югары һөнәри белем бирүче «Әлмәт дәүләт медицина хезмәте институты» дәүләт автоном мәгариф учреждениесен оештыру турында» 2010 ел, 22 февраль, 90 нчы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Гамәлгә куючының дәүләт йөкләмәсен үтәвен финанслар белән тәэмин итү, Татарстан Республикасы Хөкүмәте тарафыннан раслана торган урта һөнәри белем бирү учреждениесе мөлкәтен карап тоту нормативларыннан һәм финанс чыгымнарының тармак нормативларыннан һәм гамәлгә куючының билгеләнгән йөкләмәсеннән чыгып, дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә (эшләр башкаруга) дәүләт йөкләмәсен формалаштыру тәртибе нигезендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.»;

6 һәм 7 пунктлар үз көчен югалткан дип танырга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Башлангыч һөнәри белем бирүче «67 нче һөнәр лицее» дәүләт автоном мәгариф учреждениесен оештыру турында» 2010 ел, 23 август, 670 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Гамәлгә куючының дәүләт йөкләмәсен үтәвен финанслар белән тәэмин итү, Татарстан Республикасы Хөкүмәте тарафыннан раслана торган урта һөнәри белем бирү учреждениесе мөлкәтен карап тоту нормативларыннан һәм финанс чыгымнарының тармак нормативларыннан һәм гамәлгә куючының билгеләнгән йөкләмә-

сеннән чыгып, дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә (эшләр башкаруга) дәүләт йөкләмәсен формалаштыру тәртибе нигезендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.»;

5 пункт үз көчен югалткан дип танырга.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Балаларга өстәмә белем бирүче «Мәктәптән тыш эшләр буенча республика үзәге» дәүләт автоном мәгариф учреждениесен оештыру турында» 2010 ел, 30 декабрь, 1137 нче карарына, 4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«4. Гамәлгә куючының дәүләт йөкләмәсен үтәвен финанслар белән тәэмин итү, Татарстан Республикасы Хөкүмәте тарафыннан раслана торган урта һөнәри белем бирү учреждениесе мөлкәтен карап тоту нормативларыннан һәм финанс чыгымнарының тармак нормативларыннан һәм гамәлгә куючының билгеләнгән йөкләмәсеннән чыгып, дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә (эшләр башкаруга) дәүләт йөкләмәсен формалаштыру тәртибе нигезендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.».

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Белем бирү учреждениеләрен башлангыч һөнәр белеме бирүче «39 нчы һөнәр училищесы» дәүләт бюджет белем учреждениесен урта һөнәр белеме бирүче «Кукмара аграр көллияте» дәүләт автоном белем учреждениесенә кушу юлы белән үзгәртеп оештыру турында» 2010 ел, 30 декабрь, 1140 нчы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Гамәлгә куючының дәүләт йөкләмәсен үтәвен финанслар белән тәэмин итү, Татарстан Республикасы Хөкүмәте тарафыннан раслана торган урта һөнәри белем бирү учреждениесе мөлкәтен карап тоту нормативларыннан һәм финанс чыгымнарының тармак нормативларыннан һәм гамәлгә куючының билгеләнгән йөкләмәсеннән чыгып, дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә (эшләр башкаруга) дәүләт йөкләмәсен формалаштыру тәртибе нигезендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.»;

5 һәм 6 пунктлар үз көчен югалткан дип танырга.

5. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Урта һөнәри белем бирүче «Нурлат аграр техникумы» дәүләт автоном белем учреждениесен оештыру турында» 2011 ел, 29 июнь, 527 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 ел, 24 сентябрь, 792 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктта «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Югары һөнәри белем бирүче «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесенең фәнни-белем бирү кластерын оештыру турында» 2011 ел, 18 май, 397 нче карары белән расланган югары һөнәри белем бирүче «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесе» сүзләрен «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Югары белем бирүче «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесенең фәнни-белем бирү кластерын оештыру турында» 2011 ел, 18 май, 397 нче карары белән расланган югары белем бирүче «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесе» сүзләренә алмаштырырга;

5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Гамәлгә куючының дәүләт йөкләмәсен үтәвен финанслар белән тәэмин итү, Татарстан Республикасы Хөкүмәте тарафыннан раслана торган урта һөнәри белем

бирү учреждениесе мөлкәтен карап тоту нормативларыннан һәм финанс чыгымнарының тармак нормативларыннан һәм гамәлгә куючының билгеләнгән йөкләмәсеннән чыгып, дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә (эшләр башкаруга) дәүләт йөкләмәсен формалаштыру тәртибе нигезендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.»;

6 пункт үз көчен югалткан дип танырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин